**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru

ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.04.2019 № 312

**Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, опекага (попечительлеккә) гаиләләргә асрамага бирелгән балаларны карап тору өчен ай саен акча түләү һәм үз вазифаларын башкарган опекуннарны яки попечительләрне бүләкләү буенча эшне оештыру турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның төп принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль Закон нигезендә, “Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен тапшыру турында”гы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында”гы 2019 елның 18 мартындагы 21 Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР ЧЫГАРА:**

1. Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы опека һәм попечительлек секторына һәр айның 5 числосына кадәр “Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” МКУга ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны карап торган өчен түләүләрне башкаруга гариза һәм документлар күчермәсен тапшырырга.
2. “Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” МКУга 2019 елның 1 апреленнән һәр айның 20 числосына кадәр ятим балаларны һәм опекага (попечительлеккә) гаиләләргә асрамага бирелгән ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны карап тору өчен ай саен акча түләп тору һәм үз вазифаларын башкарган опекуннарга яки попечительләргә бүләкләү буенча эшне оештырырга.
3. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында” (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Г.Ф. Кирилинага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Б. Семенычев**